Әлмәт Шәһәр Башлыгы
карары

10 октябрь 2019 ел № 33

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гавами тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Гафиатуллин урамы, 3А адресы, 16:45:010116:7410 кадастор номерлы җир кишәрлеген межанлау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты – 2019 елның 18 октябре 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү сроклары -әлеге карар басылып чыкканнан соң кимендә бер айдан ким һәм өч айдан артык түгел.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт.

2.4. Җир кишәрлеген межанлау проекты буенча җәмәгать тыңлауларында катнашуга тәкъдимнәр һәм искәрмәләр «Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә тапшырылырга тиеш.

Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай пр-кт, 9а йорты, каб. 6.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү вакыты 2019 елның 18 октябренә кадәр.

3. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» Муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р. Р.) халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә үткәрү эшен оештырырга.

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А.Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.М. Токарев